| 11. | Статья 28. Социальная защита работников культуры<br><br>На педагогических работников организаций, осуществляющих образовательную деятельность по образовательным программам в области культуры и искусств, распространяется законодательство об образовании Российской Федерации и Республики Татарстан.<br>Органы государственной власти, органы местного самоуправления и организации в соответствии с их компетенцией могут за счет собственных средств предоставлять работникам культуры дополнительные социальные льготы в порядке, установленном законодательством.<br>Работникам организаций (учреждений) культуры, искусства и кинематографии, находящихся в ведении Республики Татарстан и расположенных в сельской местности, предоставляются меры социальной поддержки, предусмотренные для работников агропромышленного комплекса.<br>Молодым специалистам (выпускникам профессиональных образовательных организаций и образовательных организаций высшего образования, осуществляющих образовательную деятельность по образовательным программам в области культуры и искусств), прибывшим на работу в организации (учреждения) культуры, искусства и кинематографии, находящиеся в ведении Республики Татарстан и расположенные в сельской местности, выплачивается единовременное пособие в порядке, | | Статья 28. Социальная защита работников культуры<br><br>На педагогических работников организаций, осуществляющих образовательную деятельность по образовательным программам в области культуры и искусств, распространяется законодательство об образовании Российской Федерации и Республики Татарстан.<br>Органы государственной власти, органы местного самоуправления и организации в соответствии с их компетенцией могут за счет собственных средств предоставлять работникам культуры дополнительные социальные льготы в порядке, установленном законодательством.<br>Работникам организаций (учреждений) культуры, искусства и кинематографии, находящихся в ведении Республики Татарстан и расположенных в сельской местности, предоставляются меры социальной поддержки, предусмотренные для работников агропромышленного комплекса.<br>Молодым специалистам (выпускникам профессиональных образовательных организаций и образовательных организаций высшего образования, осуществляющих образовательную деятельность по образовательным программам в области культуры и искусств), прибывшим на работу в организации (учреждения) культуры, искусства и кинематографии, находящиеся в ведении Республики Татарстан и расположенные в сельской местности, выплачивается единовременное пособие в порядке, установлен- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | установленном для молодых специалистов, окончивших профессиональные образовательные организации и образовательные организации высшего образования, осуществляющие образовательную деятельность по образовательным программам в области сельского хозяйства.<br>Меры социальной поддержки специалистов муниципальных организаций (учреждений) культуры, искусства и кинематографии устанавливаются органами местного самоуправления. | статью 28 дополнить частью шестой следующего содержания:<br>«Члены творческих союзов и ассоциаций, а также другие творческие работники, не являющиеся членами творческих союзов, единственным источником доходов которых является авторское вознаграждение, имеют право на страховую пенсию при условии уплаты страховых взносов в Пенсионный фонд Российской Федерации.» | ном для молодых специалистов, окончивших профессиональные образовательные организации и образовательные организации высшего образования, осуществляющие образовательную деятельность по образовательным программам в области сельского хозяйства.<br>Меры социальной поддержки специалистов муниципальных организаций (учреждений) культуры, искусства и кинематографии устанавливаются органами местного самоуправления.<br>**Члены творческих союзов и ассоциаций, а также другие творческие работники, не являющиеся членами творческих союзов, единственным источником доходов которых является авторское вознаграждение, имеют право на страховую пенсию при условии уплаты страховых взносов в Пенсионный фонд Российской Федерации**. |
| 12. | Статья 31. Политика и приоритеты международных культурных обменов<br><br>К числу приоритетных направлений международных культурных обменов Республики Татарстан | | Статья 31. Политика и приоритеты международных культурных обменов<br><br>К числу приоритетных направлений международных культурных обменов Республики Татарстан |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | относятся:<br>совместное производство культурных ценностей;<br>охрана и реставрация уникальных памятников истории культуры;<br>подготовка кадров в области культуры и искусств;<br>создание и внедрение новых технологий, технических средств, оборудования для культурной деятельности;<br>обмен образовательными программами, методическими материалами и учебно-научной литературой. | в абзаце третьем статьи 31 слова «охрана и» исключить. | относятся:<br>совместное производство культурных ценностей;<br>реставрация уникальных памятников истории культуры;<br>подготовка кадров в области культуры и искусств;<br>создание и внедрение новых технологий, технических средств, оборудования для культурной деятельности;<br>обмен образовательными программами, методическими материалами и учебно-научной литературой. |

Проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

**«Мәдәният турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ**

**1 статья**

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 - 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015 № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның тугызынчы абзацында «, мәдәният өлкәсендә педагогик эшчәнлек» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 6 статьяның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эстетик тәрбия һәм сәнгати белем, эстетик тәрбия һәм сәнгати белем алу формаларын сайлау, мәгариф турында законнар нигезендә;»;

3) 10.1 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.1 статья. **Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларына карата Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары бурычлары**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) (алга таба – мәдәни мирас объектлары) саклауны, файдалануны, популярлаштыруны һәм дәүләт тарафыннан саклануын тәэмин итәләр.»;

4) 13 статьяның өченече өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы иҗади хезмәткәрләр вәкилләре булган оешмаларга мәдәният өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен эшләүдә катнашырга мөмкинлек тәэмин итә, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә кадрлар әзерләү, эш белән

тәэмин итү, хезмәт шартлары буенча чаралар эшләгәндә алар белән киңәшләшә, аларның эшчәнлегенә катнашмый, әгәр дә башкасы Россия Федерациясе законнары белән каралмаса.»;

5) 15 статьяны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.»;

6) 16 статьяда:

а) җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.»;

7) 17 статьяда:

а) бишенче һәм сигезенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасы мәдәният учреждениеләре буенча авторлык түләү ставкасының минималь күләмен билгеләү;

инвалидларга дәүләт музейларына, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренә (исемлеген Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган федераль дәүләт музейларыннан тыш, һәм исемлеген Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы раслаган федераль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләреннән тыш) йөрү шартларын тәэмин итү);

Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.»;

8) 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 статья. **Мәдәният өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Татарстан Республикасында авыллар, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнары мәдәният өлкәсендәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне федераль законнарга нигезләнеп башкаралар.»;

9) 19 статьяның икенче өлешендәге «мәдәни мирас объектларын саклау һәм файдалану өлкәсендә» сүзләрен «мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклану өлкәсендә» сүзләре белән алмаштырырга»;

10) 21 статьяның бишенче өлешендәге икенче җөмләне төшереп калдырырга;

11) 28 статьяны түбәндәге эчтәлекле алтынчы өлеш белән тулыландырырга:

«Авторлык түләүләре бердән-бер керем чыгынаны булган иҗади берлекләр һәм ассоциацияләр әгъзалары, шулай ук иҗади берлекләр әгъзалары булмаган башка иҗади хезмәткәрләр Россия Федерациясе Пенсия фондына иминият түләүләре түләү шарты белән иминият пенсиясенә хокуклы.»;

12) 31 статьяның өченче абзацындагы «саклау һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон, 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 статьяның 7 пунктындагы «б» пунктчасыннан гайре, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазифаларын вакытлыча башкаручы

**«Мәдәният турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы Законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы проекты «Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законын актуальләштерү һәм аның аерым нигезләмәләрен федераль законнар нормаларына тәңгәлләштерү максатларында эшләнде.

2014 елның 22 октябрендә «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 315-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителә, аның белән «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законга әһәмиятле үзгәрешләр кертелә. Күрсәтелгәннәр белән бәйле рәвештә «Мәдәният турында» 1998 елның 3 июнендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – Мәдәният турында Закон) 10.1, 18, 19, 31 статьяларына тиешле төгәллек кертү ихтыяҗы барлыкка килә.

Мәдәният турында Законның 4 статьясының тугызынчы абзацы Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләренең (алга таба – Нигезләр) 4 статьясының тугызынчы абзацына тәңгәлләштерелә. Мәгариф турында законнардагы үзгәрешләрне исәпкә алып, Мәдәният турында Законның 6 статьясының бишенче абзацы Нигезләрнең 13 статьясына тәңгәлләштерелә. 13 статьяның өченче өлеше Нигезләрнең 28 статьясының икенче өлеше белән тәңгәлләштерелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты мәдәният өлкәсендә Законда чагылмаган башка вәкаләтләр башкара, шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләрен билгеләүче 16 статьяны тиешле нигезләмәләр белән тулыландыру күздә тотыла.

Закон проекты нигезендә федераль мәдәният учреждениеләренә карата федераль дәүләт хакимияте органнарының мәдәният өлкәсендә вәкаләтләренә (Нигезләрнең 37 статьясы) тәңгәлләштереп Татарстан Республикасы мәдәният учреждениеләре буенча авторлык түләү ставкасының минималь күләмен билгеләүне Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы вәкаләте дип карау тәкъдим ителә.

Закон проекты белән «Инвалидлар хокуклары турында Конвецияне ратификацияләү белән бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон нормалары нигезендә инвалидларга дәүләт музейларына, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренә йөрү шартларын тәэмин итү буенча вәкаләтләрне Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы карамагына тапшыру күздә тотыла.

Закон проекты белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының мәдәни кыйммәтләрне исәпкә алуны билгеләү вәкаләтен һәм башкарма хакимият органының мәдәният өлкәсендә мәдәни кыйммәтләрне дәүләт тарафыннан исәпкә алу буенча вәкаләтен түбәндәгегә нигезләнеп төшереп калдыру күздә тотыла. Мәдәният турында Закон нигезендә «мәдәни кыйммәтләр дип әхлакый һәм эстетик идеалллар, үз-үзеңне тоту нормалары һәм үрнәкләре, телләр, диалектлар һәм сөйләшләр, милли гореф-гадәтләр һәм йолалар, тарихи топонимнар, фольклор, сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре, әдәбият, сәнгать әсәрләре, мәдәни эшчәнлекне фәнни өйрәнүнең нәтиҗәләре һәм алымнары, тарихи-мәдәни әһәмияткә ия биналар, төзелмәләр, предметлар һәм технологияләр, тарихи-мәдәни яктан уникаль территорияләр һәм объектлар аңлашыла». Мәдәни кыйммәтләрнең һәрбер төре өчен үзенең исәпкә алу тәртибе урнаштырылган яисә гомумән урнаштырылмаган. Мәсәлән, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан исәпкә алу Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә Россия Федерациясе мәдәният Министрлыгы тарафыннан алып барыла. Музей предметларын һәм музей коллекцияләрен исәпкә алу аларның милекчеләре яисә музейлар һәм оператив идарәсендә һәм кулланыуында булган башка оешмалар тарафыннан, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган Россия Федерациясе Музейлар фонды турында нигезләмәдә билгеләнгән кагыйдәләргә һәм шартларга нигезләнеп алып барыла.

21 статьяның бишенче өлешендәге үзгәрешләр, әлеге норманы Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексына тәңгәлләштерү белән бәйле.

Мәдәният турында Законның 28 статьясын Нигезләрнең 55 статьясы нормаларына нигезләнеп, авторлык түләүләре бердән-бер керем чыгынаны булган иҗади берлекләр һәм ассоциацияләр әгъзалары, шулай ук иҗади берлекләр әгъзалары булмаган башка иҗади хезмәткәрләр Россия Федерациясе Пенсия фондына иминият түләүләре түләү шарты белән иминият пенсиясенә хокуклы дип билгеләүче алтынчы өлеш белән тулыландырырга тәкъдим ителә.

**«Мәдәният турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чаралар бүлеп бирүне таләп итми.

**«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатып торылырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле**
**Татарстан Республикасы закон актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә закон актларын үз көчен югалткан дип тану, туктатып тору, аларга үзгәрешләр кертү яисә Татарстан Республикасы закон актларын кабул итү таләп ителми.

**«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектына**

# ЧАГЫШТЫРМА ТАБЛИЦА

| № | Татарстан Республикасы Законының гамәлдәге редакциясе | Тәкъдим ителүче үзгәрешләр | Тәкъдим ителүче үзгәрешләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Законы редакциясе |
|---|---|---|---|
| 1. | 4 статья. «Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законын куллану өлкәсе<br><br>Әлеге Закон мәдәни эшчәнлекне түбәндәге өлкәләрдә җайга сала:<br>тарих һәм мәдәният ядкарьләрен ачыклау, өйрәнү, саклау, реставрацияләү һәм файдалану;<br>матур әдәбият, кинематография, сәхнә, пластика, музыка сәнгате, архитектура һәм дизайн, фото сәнгате, сәнгатьнең башка төрләре һәм жанрлары;<br>халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре, телләр, диалектлар һәм сөйләшләр, фольклор, гореф-гадәтләр һәм йолалар, тарихи топонимнар;<br>үзешчән сәнгать иҗаты;<br>музей эше һәм коллекцияләү;<br>законнарга нигезләнеп китап басу һәм китапханә эше, шулай ук басма әсәрләр иҗат итү, аларны тарату һәм файдалану белән бәйле башка мәдәни эшчәнлек, архив эше;<br>телевидение, радио һәм мәдәни хәзинәләрне барлыкка китерү һәм тарату өлкәсендә башка аудиовизуаль чаралар;<br>эстетик тәрбия, сәнгати белем, мәдәният өлкәсендә педагогик эшчәнлек;<br>мәдәният өлкәсендә фәнни тикшеренүләр; | 4 статьяның тугызынчы абзацындагы «мәдәният өлкәсендә педагогик эшчәнлек» сүзләрен төшереп калдырырга; | 4 статья. «Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законын куллану өлкәсе<br><br>Әлеге Закон мәдәни эшчәнлекне түбәндәге өлкәләрдә җайга сала:<br>тарих һәм мәдәният ядкарьләрен ачыклау, өйрәнү, саклау, реставрацияләү һәм файдалану;<br>матур әдәбият, кинематография, сәхнә, пластика, музыка сәнгате, архитектура һәм дизайн, фото сәнгате, сәнгатьнең башка төрләре һәм жанрлары;<br>халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре, телләр, диалектлар һәм сөйләшләр, фольклор, гореф-гадәтләр һәм йолалар, тарихи топонимнар;<br>үзешчән сәнгать иҗаты;<br>музей эше һәм коллекцияләү;<br>законнарга нигезләнеп китап басу һәм китапханә эше, шулай ук басма әсәрләр иҗат итү, аларны тарату һәм файдалану белән бәйле башка мәдәни эшчәнлек, архив эше;<br>телевидение, радио һәм мәдәни хәзинәләрне барлыкка китерү һәм тарату өлкәсендә башка аудиовизуаль чаралар;<br>эстетик тәрбия, сәнгати белем;<br>мәдәният өлкәсендә фәнни тикшеренүләр;<br>халыкара мәдәни алмашулар; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | халыкара мәдәни алмашулар;<br>мәдәни хәзинәләрне саклау, барлыкка китерү, тарату һәм үзләштерү өчен кирәкле материалллар, җиһазлар һәм башка чаралар җитештерү;<br>нәтиҗәсендә мәдәни хәзинәләр саклана торган, барлыкка китерелә торган, таратыла торган һәм үзләштерелә торган башка эшчәнлек. | | мәдәни хәзинәләрне саклау, барлыкка китерү, тарату һәм үзләштерү өчен кирәкле материалллар, җиһазлар һәм башка чаралар җитештерү;<br>нәтиҗәсендә мәдәни хәзинәләр саклана торган, барлыкка китерелә торган, таратыла торган һәм үзләштерелә торган башка эшчәнлек. |
| 2 | 6 статья. Мәдәният өлкәсендә кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре<br><br>Татарстан Республикасында һәр кеше һәм граждан түбәндәгеләргә хокуклы:<br>профессиональ һәм профессиональ булмаган нигездә, үз мәнфәгатьләреннән һәм сәләтләреннән чыгып, иҗат эшчәнлеге ирегенә;<br>мәдәни үзенчәлеккә;<br>законнарда билгеләнгән аерым өземтәләрдән тыш, мәдәни хәзинәләрдән, дәүләти китапханә, музей, архив фондларыннан, мәдәни эшчәнлекнең барлык өлкәләрендәге башка дәүләт җыелмаларыннан файдалану ирегенә;<br>мәдәният өлкәсендә профессиональ белем алуга;<br>мәдәният өлкәсендә иҗат берлекләре, ассоциацияләр, коммерциягә карамаган башка оешмалар төзүгә;<br>мәдәни хәзинәләрне һәм байлыкларны җитештерү, ишәйтү, саклап калу, тарату буенча һәм мәдәният өлкәсендә арадашлык буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә оешмалар төзүгә. | 6 статьяның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:<br>«эстетик тәрбия һәм сәнгати белем, эстетик тәрбия һәм сәнгати белем алу формаларын сайлау, мәгариф турында законнар нигезендә;» | 6 статья. Мәдәният өлкәсендә кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре<br><br>Татарстан Республикасында һәр кеше һәм граждан түбәндәгеләргә хокуклы:<br>профессиональ һәм профессиональ булмаган нигездә, үз мәнфәгатьләреннән һәм сәләтләреннән чыгып, иҗат эшчәнлеге ирегенә;<br>мәдәни үзенчәлеккә;<br>законнарда билгеләнгән аерым өземтәләрдән тыш, мәдәни хәзинәләрдән, дәүләти китапханә, музей, архив фондларыннан, мәдәни эшчәнлекнең барлык өлкәләрендәге башка дәүләт җыелмаларыннан файдалану ирегенә;<br>**эстетик тәрбия һәм сәнгати белем, эстетик тәрбия һәм сәнгати белем алу формаларын сайлау, мәгариф турында законнар нигезендә;**<br>мәдәният өлкәсендә иҗат берлекләре, ассоциацияләр, коммерциягә карамаган башка оешмалар төзүгә;<br>мәдәни хәзинәләрне һәм байлыкларны җитештерү, ишәйтү, саклап калу, тарату буенча һәм мәдәният өлкәсендә арадашлык буенча законнарда |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | билгеләнгән тәртиптә оешмалар төзүгә. |
| 3. | 10.1 статья. Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларына карата Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары бурычлары<br><br>Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары федераль һәм республика законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларының дәүләт тарафыннан саклануын тәэмин итәләр.<br>Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары милекчеләренә әлеге объектларны тотуда һәм саклауда ярдәм итәләр.<br>Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге мәдәни мирас объектларына карата дәүләт контролен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәни мирас объектларын саклап калу, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләти саклау өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле органнары башкара. Татарстан Республикасында федераль, муниципаль яисә хосусый милектәге мәдәни мирас объектларына карата дәүләт контроле Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла. | 10.1 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:<br>«10.1 статья. Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларына карата Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары бурычлары<br><br>Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) (алга таба – мәдәни мирас объектлары) саклауны, файдалануны, популярлаштыруны һәм дәүләт тарафыннан саклануын тәэмин итәләр. | **10.1 статья. Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларына карата Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары бурычлары**<br><br>**Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) (алга таба – мәдәни мирас объектлары) саклауны, файдалануны, популярлаштыруны һәм дәүләт тарафыннан саклануын тәэмин итәләр.** |
| 4. | 13 статья. Дәүләт һәм иҗади хезмәткәрләр оешмалары | 13 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: | 13 статья. Дәүләт һәм иҗади хезмәткәрләр оешмалары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы иҗади хезмәткәрләр оешмалары, профессиональ иҗади хезмәткәрләрнең халыкара оешмалары филиаллларын һәм бүлекчәләрен төзүгә булышлык итә.<br>Иҗади хезмәткәрләр оешмалары дәүләт белән мөнәсәбәтләрендә тигез хокуклы.<br>Татарстан Республикасы иҗади хезмәткәрләр вәкилләре булган оешмаларга мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашырга мөмкинлек тәэмин итә. | «Татарстан Республикасы иҗади хезмәткәрләр вәкилләре булган оешмаларга мәдәният өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен эшләүдә катнашырга мөмкинлек тәэмин итә, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә кадрлар әзерләү, эш белән тәэмин итү, хезмәт шартлары буенча чаралар эшләгәндә алар белән киңәшләшә, аларның эшчәнлегенә катнашмый, әгәр дә башкасы Россия Федерациясе законнары белән каралмаса.» | Татарстан Республикасы иҗади хезмәткәрләр оешмалары, профессиональ иҗади хезмәткәрләрнең халыкара оешмалары филиаллларын һәм бүлекчәләрен төзүгә булышлык итә.<br>Иҗади хезмәткәрләр оешмалары дәүләт белән мөнәсәбәтләрендә тигез хокуклы.<br>**Татарстан Республикасы иҗади хезмәткәрләр вәкилләре булган оешмаларга мәдәният өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен эшләүдә катнашырга мөмкинлек тәэмин итә, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә кадрлар әзерләү, эш белән тәэмин итү, хезмәт шартлары буенча чаралар эшләгәндә алар белән киңәшләшә, аларның эшчәнлегенә катнашмый, әгәр дә башкасы Россия Федерациясе законнары белән каралмаса.** |
| 5. | 15 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният өлкәсендә вәкаләтләре<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мәдәният өлкәсендә карамагына түбәндәгеләр керә:<br>республика дәүләт мәдәни сәясәтен билгеләүдә катнашу;<br>мәдәният өлкәсендә закон нигезендә җайга салу;<br>мәдәнияткә каралган чыгымнар өлешендә Татарстан Республикасы бюджетынраслау;<br>законнар нигезендә салым ташламалары билгеләү. | 15 статьяны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:<br>«Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.»; | 15 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният өлкәсендә вәкаләтләре<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мәдәният өлкәсендә карамагына түбәндәгеләр керә:<br>республика дәүләт мәдәни сәясәтен билгеләүдә катнашу;<br>мәдәният өлкәсендә закон нигезендә җайга салу;<br>мәдәнияткә каралган чыгымнар өлешендә Татарстан Республикасы бюджетын раслау;<br>законнар нигезендә салым ташламалары билгеләү;<br>**Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | 16 статья. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының мәдәният өлкәсендә вәкаләтләре<br><br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының мәдәният өлкәсендә карамагына түбәндәгеләр керә:<br>мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, республика максатчан программаларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру;<br>законнар нигезендә мәдәният өлкәсендә халыкара мәдәни алмашуларны координацияләү, тышкы икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыру;<br>мәдәният өлкәсендәге дәүләт хезмәт күрсәтүләрен финанслау тәртибен билгеләү;<br>үз компетенциясе чикләрендә ташламалар билгеләү;<br>законнар нигезендә республика карамагындагы дәүләт мәдәният оешмаларын оештыру, үзгәртеп кору һәм бетерү;<br>мәдәни хәзинәләрне дәүләт тарафыннан исәпкә алу тәртибен билгеләү;<br>мәдәният өлкәсендәге дәүләт хезмәт күрсәтүләре сыйфаты стандартларын раслау. | 16 статьяда:<br>а) җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;<br>б) түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:<br>«Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.»; | 16 статья. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының мәдәният өлкәсендә вәкаләтләре<br><br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының мәдәният өлкәсендә карамагына түбәндәгеләр керә:<br>мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, республика максатчан программаларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру;<br>законнар нигезендә мәдәният өлкәсендә халыкара мәдәни алмашуларны координацияләү, тышкы икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыру;<br>мәдәният өлкәсендәге дәүләт хезмәт күрсәтүләрен финанслау тәртибен билгеләү;<br>үз компетенциясе чикләрендә ташламалар билгеләү;<br>законнар нигезендә республика карамагындагы дәүләт мәдәният оешмаларын оештыру, үзгәртеп кору һәм бетерү;<br>мәдәният өлкәсендәге дәүләт хезмәт күрсәтүләре сыйфаты стандартларын раслау;<br>**Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.** |
| 7. | 17 статья. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы вәкаләтләре<br><br>Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы карамагына түбәндәгеләр керә:<br>мәдәният өлкәсендә республика дәүләт мәдәни | 17 статьяда:<br>а) бишенче һәм сигезенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;<br>б) түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:<br>«Татарстан Республикасы мәдәният учреждениеләре буенча | 17 статья. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы вәкаләтләре<br><br>Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы карамагына түбәндәгеләр керә:<br>мәдәният өлкәсендә республика дәүләт мәдәни |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сәясәтен эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;<br>дәүләт исеменнән мәдәни хәзинәләр сатып алу;<br>мәдәният эшчәнлеген мәгълүмати һәм фәнни-методик тәэмин итү;<br>мәдәни хәзинәләрне дәүләт исәбенә алу;<br>мәдәният өлкәсендә методик тәкъдимнәр әзерләү һәм раслау;<br>мәдәният оешмалары челтәре үсешен фаразлау;<br>законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;<br>мәдәният өлкәсендәге дәүләт хезмәт күрсәтүләре сыйфаты стандартларын эшләү;<br>федераль законнарга нигезләнеп мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү уздыруны оештыру өчен шартлар тудыру;<br>иҗтимагый оешмалар катнашында мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү уздыру буенча Иҗтимагый совет оештыру һәм аның турында Нигезләмә раслау;<br>мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүматны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында һәм дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштыру;<br>Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтү сыйфаты турында хезмәт күрүчеләрнең фикерләрен белдерү техник мөмкинлекләрен тәэмин итү. | авторлык түләү ставкасының минималь күләмен билгеләү;<br>инвалидларга дәүләт музейларына, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренә (исемлеген Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган федераль дәүләт музейларыннан тыш, һәм исемлеген Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы раслаган федераль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләреннән тыш) йөрү шартларын тәэмин итү);<br>Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.»; | сәясәтен эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;<br>дәүләт исеменнән мәдәни хәзинәләр сатып алу;<br>мәдәният эшчәнлеген мәгълүмати һәм фәнни-методик тәэмин итү;<br>мәдәният өлкәсендә методик тәкъдимнәр әзерләү һәм раслау;<br>мәдәният оешмалары челтәре үсешен фаразлау;<br>мәдәният өлкәсендәге дәүләт хезмәт күрсәтүләре сыйфаты стандартларын эшләү;<br>федераль законнарга нигезләнеп мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүен бәйсез бәяләү уздыруны оештыру өчен шартлар тудыру;<br>иҗтимагый оешмалар катнашында мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү уздыру буенча Иҗтимагый совет оештыру һәм аның турында Нигезләмә раслау;<br>мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүматны үзенең рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштыру;<br>Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтү сыйфаты турында хезмәт күрүчеләрнең фикерләрен белдерү техник мөмкинлекләрен тәэмин итү;<br>**Татарстан Республикасы мәдәният учреждениеләре буенча авторлык түләү ставкасының минималь күләмен билгеләү;**<br>**инвалидларга дәүләт музейларына, мәдәният** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | **һәм сәнгать учреждениеләренә (исемлеген Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган федераль дәүләт музейларыннан тыш, һәм исемлеген Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы раслаган федераль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләреннән тыш) йөрү шартларын тәэмин итү);**<br>**Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.** |
| 8. | 18 статья. Мәдәният өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре<br><br>Җирлекнең җирле үзидарә органнарының мәдәният өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:<br>халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, җирлек китапханәләренең китапханә фондларын туплау;<br>җирлек халкының ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итү өчен шартлар тудыру;<br>җирлек милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру, җирлек территориясендәге җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау;<br>җирле традицион халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, җирлектә халык сәнгать кәсепләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу. | 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:<br><br>«18 статья. Мәдәният өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре<br><br>Татарстан Республикасында авыллар, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнары мәдәният өлкәсендәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне федераль законнарга нигезләнеп башкаралар.» | **18 статья. Мәдәният өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**<br><br>**Татарстан Республикасында авыллар, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнары мәдәният өлкәсендәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне федераль законнарга нигезләнеп башкаралар.** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Муниципаль район җирле үзидарә органнарының мәдәният өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:<br>халыкка авылара китапханәләр тарафыннан китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, аларның китапханә фондларын туплау;<br>муниципаль район составына керә торган җирлекләргә аларның ялын оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүне һәм мәдәният оешмалары хезмәтләрен күрсәтүне тәэмин итү өчен шартлар тудыру;<br>муниципаль район составына керүче җирлекләрдә җирле традицион халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру.<br>Шәһәр округы җирле үзидарә органнарының мәдәният өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:<br>халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, шәһәр округы китапханәләренең китапханә фондларын туплау;<br>шәһәр округы халкының ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләрен күрсәтүне тәэмин итү өчен шартлар тудыру;<br>шәһәр округы милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру, шәһәр округы территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау;<br>шәһәр округында җирле традицион халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | халык сәнгать кәсепләрен саклауда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу. | | |
| 9. | 19 статья. Татарстан Республикасында мәдәни хәзинәләргә милекчелек хокукы<br><br>Татарстан Республикасында мәдәни хәзинәләр, аларның тарихи-мәдәни әһәмияте категориясенә бәйсез рәвештә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт милкендә, муниципаль милектә, физик һәм юридик затларның хосусый милкендә торырга мөмкин. Дәүләт милкендә генә торырга мөмкин булган мәдәни хәзинәләрнең төрләре федераль законнар белән билгеләнә.<br>Татарстан Республикасында мәдәни хәзинәләргә милекчелек хокукын алу һәм туктату, шулай ук аларга хуҗа булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү тәртибе, мәдәният турында федераль законнарда, шулай ук мәдәни мирас объектларын саклау һәм файдалану өлкәсендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, Россия Федерациясенең граждан, шәһәр төзелеше, җир законнары белән билгеләнә.<br>Татарстан Республикасында мәдәни хәзинәләрнең милекчесе, федераль һәм республика законнарында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, үзенә караган мәдәни хәзинәләрнең сакланышы өчен җаваплы була. | 19 статьяның икенче өлешендәге «мәдәни мирас объектларын саклау һәм файдалану өлкәсендә» сүзләрен «мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклану өлкәсендә» сүзләре белән алмаштырырга; | 19 статья. Татарстан Республикасында мәдәни хәзинәләргә милекчелек хокукы<br><br>Татарстан Республикасында мәдәни хәзинәләр, аларның тарихи-мәдәни әһәмияте категориясенә бәйсез рәвештә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт милкендә, муниципаль милектә, физик һәм юридик затларның хосусый милкендә торырга мөмкин. Дәүләт милкендә генә торырга мөмкин булган мәдәни хәзинәләрнең төрләре федераль законнар белән билгеләнә.<br>Татарстан Республикасында мәдәни хәзинәләргә милекчелек хокукын алу һәм туктату, шулай ук аларга хуҗа булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү тәртибе, мәдәният турында федераль законнарда, шулай ук **мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклану өлкәсендә** Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, Россия Федерациясенең граждан, шәһәр төзелеше, җир законнары белән билгеләнә.<br>Татарстан Республикасында мәдәни хәзинәләрнең милекчесе, федераль һәм республика законнарында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, үзенә караган мәдәни хәзинәләрнең сакланышы өчен җаваплы була. |
| 10. | 21 статья. Татарстан Республикасында | 21 статьяның бишенче | 21 статья. Татарстан Республикасында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | мәдәниятне һәм мәдәни эшчәнлекне финанслау чыганаклары<br>Мәдәният өлкәсендә финанс чаралар түбәндәгеләр исәбенә формалашалар:<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан мәдәнияткә бүлеп бирелгән акчадан;<br>мәдәният оешмалары эшчәнлеге керемнәреннән;<br>юридик һәм физик затларның, шулай ук халыкара оешмаларның ирекле түләүләреннән;<br>законнар белән тыелмаган башка чыганаклар чараларыннан.<br>Мәдәниятне дәүләт тарафыннан финанслау күләме чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын раслаганда билгеләнә.<br>Дәүләт мәдәният оешмаларын финанслау күләмнәре һәм нормативлары инфляция темпларына нигезләнеп индексацияләнергә тиеш.<br>Өстәмә чаралар җәлеп итү мәдәниятне бюдджеттан финанслауны киметмәячәк.<br>Финанс чараларын куллану законнар нигезендә һәм мәдәният оешмасы уставы нигезендә башкарыла. Агымдагы отчёт чорында кулланылмаган чаралар алынырга тиеш түгел һәм алга таба устав максатларында кулланыла.<br>Мәдәният оешмалары Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда һәм тәртиптә үз илебез һәм чит ил банклары кредитыннан файдаланырга, валютаны сатырга һәм сатып алырга мөмкин.<br>Мәдәният өлкәсендәге дәүләт хезмәт күрсәтүләрен Татарстан Республикасы бюджеты | өлешендәге икенче җөмләне төшереп калдырырга | мәдәниятне һәм мәдәни эшчәнлекне финанслау чыганаклары<br>Мәдәният өлкәсендә финанс чаралар түбәндәгеләр исәбенә формалашалар:<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан мәдәнияткә бүлеп бирелгән акчадан;<br>мәдәният оешмалары эшчәнлеге керемнәреннән;<br>юридик һәм физик затларның, шулай ук халыкара оешмаларның ирекле түләүләреннән;<br>законнар белән тыелмаган башка чыганаклар чараларыннан.<br>Мәдәниятне дәүләт тарафыннан финанслау күләме чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын раслаганда билгеләнә.<br>Дәүләт мәдәният оешмаларын финанслау күләмнәре һәм нормативлары инфляция темпларына нигезләнеп индексацияләнергә тиеш.<br>Өстәмә чаралар җәлеп итү мәдәниятне бюдджеттан финанслауны киметмәячәк.<br>Финанс чараларын куллану законнар нигезендә һәм мәдәният оешмасы уставы нигезендә башкарыла.<br>Мәдәният оешмалары Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда һәм тәртиптә үз илебез һәм чит ил банклары кредитыннан файдаланырга, валютаны сатырга һәм сатып алырга мөмкин.<br>Мәдәният өлкәсендәге дәүләт хезмәт күрсәтүләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау нормативлары мәдәният өлкәсендәге дәүләт хезмәт күрсәтүләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | акчалары исәбеннән финанслау нормативлары мәдәният өлкәсендәге дәүләт хезмәт күрсәтүләре сыйфаты стандартлары нигезендә формалаша. | | сыйфаты стандартлары нигезендә формалаша. |
| 11. | 28 статья. Мәдәният хезмәткәрләрен социаль яклау<br>Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеге башкарган педагогик хезмәткәрләргә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы мәгариф турында законнары кагыла.<br>Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалары аларның компетенцияләренә нигезләнеп үз хисапларына мәдәният хезмәткәрләренә өстәмә социаль ташламалар бирергә мөмкин.<br>Татарстан Республикасы карамагындагы һәм авыл җирлегендә урнашкан мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмалары (учреждениеләре) хезмәткәрләренә агросәнәгать комплексы хезмәткәрләре өчен каралган социаль ярдәм чаралары бирелә.<br>Татарстан Республикасы карамагындагы һәм авыл җирлегендә урнашкан мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларына (учреждениеләренә) эшкә килгән яшь белгечләргә (мәдәният һәм сәнгать югары һәм махсус урта уку йортларын тәмамлаучыларга) авыл хуҗалыгы югары һәм махсус урта уку йортларын тәмамлаган яшь белгечләр өчен билгеләнгән тәртиптә бер мәртәбә пособие түләнә.<br>Мәдәниятнең, сәнгатьнең һәм | 28 статьяны түбәндәге эчтәлекле алтынчы өлеш белән тулыландырырга:<br>«Авторлык түләүләре бердән-бер керем чыганаы булган иҗади берлекләр һәм ассоциацияләр әгъзалары, шулай ук иҗади берлекләр әгъзалары булмаган башка иҗади хезмәткәрләр Россия Федерациясе Пенсия фондына иминият түләүләре түләү шарты белән иминият пенсиясенә хокуклы.» | 28 статья. Мәдәният хезмәткәрләрен социаль яклау<br>Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеге башкарган педагогик хезмәткәрләргә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы мәгариф турында законнары кагыла.<br>Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалары аларның компетенцияләренә нигезләнеп үз хисапларына мәдәният хезмәткәрләренә өстәмә социаль ташламалар бирергә мөмкин.<br>Татарстан Республикасы карамагындагы һәм авыл җирлегендә урнашкан мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмалары (учреждениеләре) хезмәткәрләренә агросәнәгать комплексы хезмәткәрләре өчен каралган социаль ярдәм чаралары бирелә.<br>Татарстан Республикасы карамагындагы һәм авыл җирлегендә урнашкан мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларына (учреждениеләренә) эшкә килгән яшь белгечләргә (мәдәният һәм сәнгать югары һәм махсус урта уку йортларын тәмамлаучыларга) авыл хуҗалыгы югары һәм махсус урта уку йортларын тәмамлаган яшь белгечләр өчен билгеләнгән тәртиптә бер мәртәбә пособие түләнә.<br>Мәдәниятнең, сәнгатьнең һәм |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кинематографиянең муниципаль оешмалары (учреждениеләре) белгечләренә социаль ярдәм чаралары җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә. | | кинематографиянең муниципаль оешмалары (учреждениеләре) белгечләренә социаль ярдәм чаралары җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.<br>**Авторлык түләүләре бердән-бер керем чыгынаны булган иҗади берлекләр һәм ассоциацияләр әгъзалары, шулай ук иҗади Авторлык түләүләре бердән-бер керем чыгынаны булган иҗади берлекләр әгъзалары булмаган башка иҗади хезмәткәрләр Россия Федерациясе Пенсия фондына иминият түләүләре түләү шарты белән иминият пенсиясенә хокуклы.** |
| 12. | 31 статья. Халыкара мәдәни алмашулар сәясәте һәм өстенлекләре<br><br>Татарстан Республикасының халыкара мәдәни алмашулар өстенлекле юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:<br>мәдәни хәзинәләрне уртак җитештерү;<br>мәдәният тарихы уникаль ядкарьләрен саклау һәм реставрацияләү;<br>мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә кадрлар әзерләү;<br>мәдәни эшчәнлек өчен яңа технологияләр, техник чаралар, җиһазлар булдыру һәм кертү;<br>белем бирү программалары, методик материаллар һәм уку-фәнни әдәбият белән алмашу. | 31 статьяның өченче абзацындагы «саклау һәм» сүзләрен төшереп калдырырга. | 31 статья. Халыкара мәдәни алмашулар сәясәте һәм өстенлекләре<br><br>Татарстан Республикасының халыкара мәдәни алмашулар өстенлекле юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:<br>мәдәни хәзинәләрне уртак җитештерү;<br>мәдәният тарихы уникаль ядкарьләрен реставрацияләү;<br>мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә кадрлар әзерләү;<br>мәдәни эшчәнлек өчен яңа технологияләр, техник чаралар, җиһазлар булдыру һәм кертү;<br>белем бирү программалары, методик материаллар һәм уку-фәнни әдәбият белән алмашу. |

КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

27.06.2015 г.Казань № 1388-р

1. Внести в Государственный Совет Республики Татарстан проект закона Республики Татарстан «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О культуре», одобренный в установленном порядке Межведомственным координационным комитетом по правовым вопросам.

2. Назначить министра культуры Республики Татарстан А.М.Сибагатуллина официальным представителем Кабинета Министров Республики Татарстан – Правительства Республики Татарстан при рассмотрении Государственным Советом Республики Татарстан проекта закона Республики Татарстан «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О культуре».

Премьер-министр
Республики Татарстан И.Ш.Халиков

АППАРАТ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
№1
УПРАВЛЕНИЕ ДОКУМЕНТАЦИОННОГО СОПРОВОЖДЕНИЯ